| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 октябрь г.Казань № 944

Татарстан Республикасы Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16+200 км – 21+977 км» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегенең 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Главтатдортранс) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16+200 км – 21+977 км» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында торак пункт җирләре категориясеннән барлыкка килә торган 16:33:080201:163 кадастр номерлы, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге, Иске Кощаково авылы, Луговая урамы, 2 нче җир участогы (алга таба – җир участогы) адресы буенча урнашкан, Серебренникова Л.С. милкендә булган (алга таба – җир кишәрлеге милекчесе) 170 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алу юлы белән алу турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән алына торган җир кишәрлеген урнаштыру схемасын расларга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга;

Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны бастырып чыгарырга;

әлеге карарның күчермәләрен Главтатдортрански, җир кишәрлеге милекчесенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң, Баштатдортранс белән берлектә, Татарстан Республикасы Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында Килешү (алга таба – килешү) әзерләү һәм аның җир кишәрлеге хуҗасына җибәрү өчен 30 көнлек срок эчендә;

килешү төзергә

җир кишәрлеге өчен түләргә;

җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәве;

җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан закон белән билгеләнгән срокта кул куелган килешү тапшырылмаган очракта судка тиешле дәгъвалар бирергә.

4. Главтатдортрански 16:33:080201:163 кадастр санлы җир кишәрлегенә карата һәм әлеге карар белән расланган алына торган җир кишәрлегенең урнашу схемасы буенча кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин